СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.05.2025 № 58/8
На №_________от_____________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 29 маендагы 22/9 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елның 01 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 29 маендагы 22/9 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктчаны өстәргә:

«13) өч һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы ата-аналар, өлкән бала унсигез яшькә яки, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән, егерме өч яшькә җиткәнче.».

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ТУКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ · ОГРН 1051667007039 · р 05-11818/09 · Совет ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА · ИНН 1639031685